Республика Татарстан

СОВЕТ ШАРЛИАРЕМИНСКОГО СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ САРМАНОВСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА

ул. Школьная, д. 57, д.Шарлиарема
423378
Телефон: 4-57-55

Татарстан Республикасы

САРМАН МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ ШӘРЛӘРӘМӘ АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ СОВЕТЫ

Мәктәп урамы, йорт 57, Шәрләрәмә авылы 423378
Телефон: 4-57-55

ОГРН 1121651003671 ИНН/КПП 1636007010/163601001 ОКТМО 92653482

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

20 март 2017 ел № 1

Сарман муниципаль районы " Шәрләрәмә авыл җирлеге» муниципаль берәмлегенең җирдән файдалану һәм төзелеш кагыйдәләренә үзгәрешләр кертү турында проект буенча ачык тыңлаулар билгеләү хакында

Россия Федерациясе Шәһәр төзелеше кодексының 31 статьясына, «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 28 статьясына, Татарстан Республикасы Сарман муниципаль районының «Шәрләрәмә авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Уставына, Татарстан Республикасы Сарман муниципаль районы Шәрләрәмә авыл җирлегендә 2007 елның 7 июлендәге 13 номерлы карары белән расланган ачык тыңлауларны оештыру һәм үткәрү тәртибе турындагы нигезләмәгә таянып, карар бирәм::

1. Татарстан Республикасы Сарман муниципаль районы «Шәрләрәмә авыл җирлеге» муниципаль берәмлегенең җирдән файдалану һәм төзелеш кагыйдәләренә үзгәрешләр кертү турындагы проект буенча ачык тыңлаулар билгеләргә.

2. Билгеләү:

- Шәрләрәмә авыл җирлегеннән файдалану һәм төзелеш Кагыйдәләре проектын әзерләү буенча ачык тыңлауларны оештыручы - комиссия;

- ачык тыңлаулар үткәрү вакыты-2017 елның 20 апрелендә 10.00 сәгать;

үткәрү урыны: Татарстан Республикасы, Шәрләрәмә авылы, Школьная ур., 57, Сарман муниципаль районы Шәрләрәмә авыл җирлеге Советы;

- фикер алышына торган мәсьәлә буенча язмача тәкъдимнәр һәм искәрмәләр кертелә торган адрес: ТР, Шәрләрәмә авылы, Школьная ур., 57, Совет

Сарман муниципаль районы Шәрләрәмә авыл җирлеге (эш көннәрендә 7.00 дән 16.30 сәгатькә кадәр (төшке аш 11.30 дан 13.00 сәгатькә кадәр).

4. Шәрләрәмә авыл җирлегендә җирдән файдалану һәм төзелеш Кагыйдәләре проектын әзерләү буенча комиссия:

- Татарстан Республикасы Сарман муниципаль районы « Шәрләрәмә авыл җирлеге» муниципаль берәмлегенең җирдән файдалану һәм төзелеш кагыйдәләренә үзгәрешләр кертү турындагы проект буенча гамәлдәге законнар һәм әлеге карар белән билгеләнгән срокларда ачык тыңлаулар әзерләргә һәм үткәрергә;;

- ачык тыңлаулар үткәрү нәтиҗәләре турында бәяләмә әзерләргә һәм аны билгеләнгән тәртиптә 2017 елның 20 апреленнән дә соңга калмыйча бастырып чыгарырга;;

- Татарстан Республикасы Сарман муниципаль районы «Шәрләрәмә авыл җирлеге» муниципаль берәмлегенең җирдән файдалану һәм төзелеш кагыйдәләренә үзгәрешләр кертү турындагы проектны Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге Сарман муниципаль районының рәсми сайтында веб-адрес буенча урнаштырырга: http://sarmanovo.tatarstan.ru/

5. Әлеге карарны «Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында» урнаштыру юлы белән түбәндәге веб-адрес буенча игълан итәргә: http://pravo.tatarstan.ru - Сарман муниципаль районының рәсми сайтында интернет-телекоммуникация челтәре буенча танышырга була. sarmanovo.tatarstan.ru к

6. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотам.

Шәрләрәмә авыл җирлеге башлыгы: Хуҗина Н.Н.